Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең Елаур авылында узган
халык җыены карары

21 февраль 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2022 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

МТЗ-82.1 тракторын һәм аңа тагылмалы җиһазлар алу өчен;
Елаур торак пунктында Бөек Ватан сугышында катнашкан якташларга һәйкәл ясау (төзелеш материаллары сатып алу, фундамент салу (төзү) һәм обелиск урнаштыру, мәгълүмати стендлар, язулар һәм аларны урнаштыру, коймa тоту, буяу, юлга плитка алып җәю, бордюрлар, керамогранит урнаштыру, куак үсентеләре, чәчәк культуралары орлыклары сатып алу, кара туфрак сатып алу һәм территорияне төзекләндерү, килешү буенча эшләр өчен түләү, транспорт хезмәтләре күрсәтү өчен түләү).

Халык җыенында рәислек итүче: О.В.Охотникова

Елаур авыл җирлеге башлыгы: О.В.Охотникова